| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 август, 2020 ел № 41/5

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне кушымтада каралган тәртиптә расларга.

2. Көчен югалткан дип таныргa:

1) Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәне раслау хакында» 26/6 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2013 ел, 18 сентябрьдәге 70 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2013 ел, 18 сентябрьдәге 70 санында басылган;

2) Шәһәр Советының 2013 елның 19 декабрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 28/7 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2014 ел, 10 гыйнвардагы 1 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2014 ел, 10 гыйнвардагы 1 санында басылган;

3) Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 33/6 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2014 ел, 17 октябрьдәге 78 санында басылган;

4) Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 39/6 номерлы Карарын, «Челнинские известия»

газетасының 2015 ел, 6 майдагы 32 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2015 ел, 22 апрельдәге 29 санында басылган;

5) Шәһәр Советының 2016 елның 24 февралендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 6/6 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2016 ел, 4 марттагы 16 санында басылган;

6) Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 20/5 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2017 ел, 1 ноябрьдәге 81 санында басылган;

7) Шәһәр Советының 2018 елның 21 февралендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 23/7 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2018 ел, 7 март, 16 санында басылган;

8) Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 26/7 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2018 ел, 17 августтагы 60 санында «Шәһри Чаллы» газетасының 24 августтагы 61 санында басылган;

9) Шәһәр Советының 2018 елның 8 ноябрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 27/5 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2018 ел, 14 ноябрьдәге 82 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 16 ноябрьдәге 83 санында басылган;

10) Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 29/7 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 209 ел, 30 гыйнвардагы 6 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 30 гыйнвардагы 6 санында басылган;

11) Шәһәр Советының 2019 елның 7 октябрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 33/5 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2019 ел, 16 октябрьдәге 76 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2019 ел, 23 октябрьдәге 78 санында басылган.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме — Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
41/5 Карарына кушымта
11 август, 2020 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында
Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты (алга таба – шәһәр бюджеты) төзү һәм карау, шәһәр бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен контрольдә тоту, бюджет исәбен алу, төзү, тышкы тикшерү, бюджет хисабын карау һәм раслау тәртибен билгели.

2. Терминнар һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Бюджет Кодексында кулланылган мәгънәдә кулланыла.

3. Бюджет процессының төп этаплары булып тора:

1) шәһәр бюджеты проектын төзү;

2) шәһәр бюджетын карау һәм раслау;

3) шәһәр бюджеты үтәлеше;

4) шәһәр бюджеты үтәлешен контрольдә тоту;

5) бюджет исәбен гамәлгә ашыру;

6) бюджет хисабын төзү, тышкы тикшерү, карау һәм раслау.

4. Шәһәр бюджеты проекты Башкарма комитет тарафыннан бер елга (чираттагы финанс елына) яки өч елга (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда төзелә.

5. Шәһәр бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турындагы хисап әлеге нигезләмә һәм Шәһәр Советының башка карарлары белән билгеләнгән тәртиптә җәмәгать тыңлауларында фикер алышканнан соң карап тикшерелергә һәм расланырга тиеш.

6. Шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы карары проекты Шәһәр Советы каравына Башкарма комитет тарафыннан агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча түбәндәге документлар һәм материаллар белән бер үк вакытта кертелә:

1) шәһәрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

2) агымдагы финанс елының узган чорында шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенең якынча йомгаклары һәм агымдагы финанс елында шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенең көтелгән нәтиҗәләре;

3) шәһәрнең социаль-икътисадый үсеше фаразы;

4) чираттагы финанс елына һәм план чорына төп характеристикалар фаразы (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме,шәһәр бюджеты дефициты (профициты) яисә расланган уртача сроклы финанс планы;

5) шәһәр бюджеты проектына аңлатма язмасы, Шәһәр Советы карары проектында бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм

бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне кушымта итеп, - шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы карары проектында бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү хакында кушымта булмаган очракта;

6) чираттагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына һәм план чорының һәр елына (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке бурычның иң югары чиге һәм (яисә) муниципаль тышкы бурычның иң югары чиге;

7) агымдагы финанс елына шәһәр бюджетының көтелгән үтәлешен бәяләү;

8) күрсәтелгән бюджет сметаларына карата финанс органы белән каршылыклар барлыкка килгән очракта тапшырыла торган Шәһәр Советы, Контроль-хисап палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектлары;

9) чыгым йөкләмәләре реестры;

10) хисап финанс елына салым чыгымнарын бәяләү, агымдагы финанс елына салым чыгымнарын бәяләү һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына салым чыгымнарын бәяләү турында хисап;

11) шәһәр бюджеты керемнәре чыганаклары реестры;

12) муниципаль программалар һәм программа булмаган эшчәнлек юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы карары белән расланган очракта, муниципаль программалар паспортлары, күрсәтелгән паспортларга үзгәрешләр проектлары.

7. Башкарма комитет тарафыннан шәһәр бюджеты турындагы карар проекты Шәһәр Советы каравына кертелгәннән соң ике эш көне эчендә шәһәр Хакиме аны Шәһәр Советының бюджет буенча эш органына (алга таба - Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә) җибәрә.

8. Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясе әлеге проектны алганнан соң өч эш көне эчендә шәһәр бюджеты проектының, тапшырылган документларның һәм материалларның Россия Федерациясе бюджет законнарына туры килүе турында бәяләмә әзерли.

9. Шәһәр Хакиме Шәһәр Советының социаль-икътисадый мәсьәләләре үсеш һәм бюджет буенча даими комиссиясе бәяләмәсе нигезендә Шәһәр Советы тарафыннан шәһәр бюджеты турында карар проектын карап тикшерүгә алу яки аны эшләп бетерү өчен Башкарма комитетка кире кайтару турында карар кабул итә.

10. Эшләп бетерү өчен кергән көннән алып биш эш көне эчендә шәһәр бюджеты турындагы карар проекты барлык кирәкле документлар һәм материаллар белән Башкарма комитет тарафыннан Шәһәр Советиына тәкъдим ителергә тиеш.

11. Шәһәр бюджеты турындагы карар проекты Шәһәр Советына карауга кертелгән көннән алып өч эш көне эчендә Хаким тарафыннан Шәһәр Советының даими комиссияләренә искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү өчен, Контроль-хисап палатасына бәяләмә әзерләү өчен җибәрелә.

12. Шәһәр Советының даими комиссияләре шәһәр бюджеты турындагы карар проектын карый һәм аңа бәяләмәләр, төзәтмәләр һәм рекомендацияләр әзерли.

13. Шәһәр бюджеты турындагы карар проектын карау нәтиҗәләре буенча Шәһәр Советының даими комиссияләре Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә бәяләмәләр, төзәтмәләр һәм рекомендацияләр җибәрә.

14. Алынган бәяләмәләр нигезендә Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясе шәһәрнең социаль-икътисадый үсеше фаразы, Шәһәр Советының шәһәр бюджеты турындагы карары проекты буенча гомумиләштерелгән бәяләмә әзерли.

15. Шәһәр бюджеты чыгымнарының аерым юнәлешләрен арттыруны күздә тоткан төзәтмәләрдә башка юнәлешләр буенча финанслауны киметү яисә чын өстәмә керем чыганагын күрсәткән тәкъдимнәр булырга тиеш.

16. Шәһәр бюджетының чыгым өлешенә төзәтмәләрне караганда, башта чыгымнарны киметүне күздә тоткан төзәтмәләр карала һәм раслана, ә аннары шәһәр бюджетының чыгым өлешен арттыруны күздә тоткан төзәтмәләр карала һәм раслана.

17. Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенең гомумиләштерелгән бәяләмәсе нигезендә Башкарма комитет шәһәр бюджеты турында карар проектын эшләп бетерә һәм карау өчен Шәһәр Советына тапшыра.

18. Шәһәр бюджеты турындагы карар проекты Шәһәр Советы тарафыннан мәсьәләләрне карау календарена кертелә.

19. Шәһәр бюджеты турындагы карар проекты һәм аны Шәһәр Советында карау буенча гариза бирү хокукына Башкарма комитет Җитәкчесе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы ия.

20. Шәһәр Советы утырышында шәһәр бюджеты турындагы карар проектын караганда, Шәһәр Советы Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы докладын һәм Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясе рәисенең өстәмә докладын тыңлый һәм шәһәр бюджеты проектын раслау турында карар кабул итә.

21. Агымдагы финанс елына һәм план чорына шәһәр бюджетына үзгәрешләр кертү турында Шәһәр Советы карары проекты Башкарма комитет тарафыннан эшләнә һәм түбәндәге документлар һәм материаллар белән бергә, Шәһәр Советына тапшырыла:

1) агымдагы финанс елында көтелүче социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре һәм план чорында социаль-икътисадый үсешнең төгәл фаразлары;

2) агымдагы финанс елының узган хисап чорында шәһәр бюджеты үтәлеше турында белешмәләр, шул исәптән бүлекләр, бүлекчәләр, максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), шәһәр бюджеты чыгымнары төрләре төркемнәре буенча;

3) агымдагы финанс елында шәһәр бюджетының көтелгән үтәлеше бәяләмәсе;

4) агымдагы финанс елы һәм план чоры арасында агымдагы финанс елының узган хисап чорында шәһәр бюджеты чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган юнәлешләр), чыгымнар төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен яңадан бүлү турында мәгълүмат;

5) агымдагы финанс елының узган хисап чорында шәһәр бюджеты чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган юнәлешләр) буенча расланган бюджет ассигнованиеләре составында резервланган бюджет ассигнованиеләрен яңадан бүлү турында мәгълүмат;

6) «Шәһәр бюджетына үзгәрешләр кертү турында» Шәһәр Советы карары проектына аңлатма язуы.

22. Шәһәр бюджетын үтәү Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә Башкарма комитет тарафыннан тәэмин ителә.

Бюджет үтәлеше Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә җыелма бюджет язмасы һәм касса планы нигезендә оештырыла.

23. Башкарма комитетның финанс органы бюджет һәм акчалата йөкләмәләрне исәпкә кую, акчалата йөкләмәләрне түләүне санкцияләүдә түбәндәгеләрне контрольдә тота:

1) бюджет йөкләмәләренең тиешле лимитларына яисә бюджет акчаларын алучыга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләренә, шулай ук бюджет йөкләмәсе турындагы мәгълүматның бюджет чыгымнары классификациясе кодына туры килүен;

2) тиешле бюджет йөкләмәсе турында исәпкә куелган мәгълүматның акчалата йөкләмә турында мәгълүматка туры килүен;

3) акчалата йөкләмәне түләү өчен түләү документында күрсәтелгән мәгълүматның, акчалата йөкләмә турында мәгълүматка туры килүен;

4) акчалата йөкләмә барлыкка килүне раслаучы документлар булуын.

24. Бюджет йөкләмәсе муниципаль контракт нигезендә барлыкка килгән очракта, өстәмә рәвештә дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында каралган контрактлар реестрындагы белешмәләрнең һәм муниципаль контракт нигезендә барлыкка килгән бюджет йөкләмәсе, муниципаль контракт шартларына туры килүен өстәмә контрольгә алу гамәлгә ашырыла.

Акчалата йөкләмәләрне түләү (гавами норматив йөкләмәләр буенча акчалата йөкләмәләрдән тыш) бюджет акчаларын алучыга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

25. Шәһәр бюджеты үтәлешен контрольдә тоту муниципаль финанс контролен уздыру юлы белән башкарыла.

26. Бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, шәһәр бюджетыннан физик затларга башка түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләр һәм йөкләмәләр бирә торган хокукый актлар нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итү, шулай ук бюджеттан акча бирү турында муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү

максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган тәртиптә муниципаль финанс контроле гамәлгә ашырыла.

27. Муниципаль финанс контроле тышкы һәм эчке, башлангыч һәм дәвам ителүче төрләргә бүленә.

28. Тышкы муниципаль финанс контроле Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.

Эчке муниципаль финанс контроле-муниципаль финанс контроле органы буларак Башкарма комитетның финанс органының контроль эшчәнлеге булып тора.

29. Бюджет үтәлеше турындагы хисапта Россия Федерациясе бюджет классификациясе нигезендә керемнәр, чыгымнар һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет үтәлеше турындагы белешмәләр туплана.

30. Башкарма комитетның финанс органы бюджет хисабын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыра.

31. Бюджет исәбе Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең финанс һәм финанс булмаган активларының һәм йөкләмәләренең торышы турында акчалата чагылыштагы мәгълүматны җыю, теркәү һәм гомумиләштерүнең, шулай ук әлеге активларны һәм йөкләмәләрне үзгәртә торган операцияләр турында мәгълүмат җыюның, теркәүнең һәм гомумиләштерүнең җайга салынган системасыннан гыйбарәт.

32. Бюджет исәбе Россия Федерациясенең бюджет классификациясен үз эченә алган счетлар планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

33. Бюджет хисабына түбәндәгеләр керә:

1) бюджет үтәлеше турында хисап;

2) бюджет үтәлеше балансы;

3) эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында хисап;

4) акча хәрәкәте турында хисап;

5) аңлатма язуы.

34. Бюджет үтәлеше турындагы хисапта Россия Федерациясе бюджет классификациясе нигезендә керемнәр, чыгымнар һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет үтәлеше турындагы белешмәләр туплана. Шәһәр бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап Шәһәр Советында каралганчы тышкы тикшерү узарга тиеш, ул бюджет акчаларының баш администраторларының бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерүне һәм бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә ала.

35. Шәһәр бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Контроль-хисап палатасы тарафыннан башкарыла.

36. Башкарма комитет, бәяләмә әзерләү өчен, шәһәр бюджеты үтәлеше турында хисапны агымдагы елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча бирә. Шәһәр бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә әзерләү бер айдан да артмаган срокта башкарыла.

37. Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Контроль-хисап палатасы тарафыннан бер үк вакытта Шәһәр Советына һәм Башкарма комитетка тапшырыла.

38. Шәһәр Советының бюджет үтәлеше турындагы карары проекты белән хисап финанс елына бюджет үтәлеше турындагы хисап раслана, анда бюджет керемнәренең, чыгымнарының һәм бюдџет кытлыгының (профицитының) гомуми күләме күрсәтелә.

39. Шәһәр бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап Шәһәр Советына агымдагы елның 1 маеннан да соңга калмыйча тапшырыла.

40. Агымдагы финанс елының беренче кварталында, ярты еллыгында һәм тугыз аенда шәһәр бюджеты үтәлеше турындагы хисап Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан раслана һәм Шәһәр Советына һәм Контроль-хисап палатасына җибәрелә.